**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 03 » 11 2020 № 692

Аксубаево

2021 елга «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең
балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында
өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә
норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 14.12.2009 ел, №854 карары һәм «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга расларга:

«Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнарны;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга төзәтү коэффициентын 0,5 күләмендә.

2.Аксубай муниципаль районының Финанс бюджет палатасына, әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә, балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга: http:/ / pravo. tatarstan. ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Александровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль
районы Башкарма
комитеты җитәкчесенең
«03» 11 2020 № 692
карары белән расланган

«Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә
норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар (1 укучыга бер елга сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | Җиде еллык уку вакыты | башлангыч һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыкаль сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 55 793 | 64 719 | 84 130 |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| рәсем сәнгате | шәһәр җирлеге | | 30 808 | | 26 803 | 64 347 |
| рәсем сәнгате | авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 58 474 | 48 228 | 175 835 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 25 592 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 55 174 | 52 945 | 85 700 |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 84 971 | | 81 330 | | 134 297 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 43 848 | | 40 718 | 40 728 | 64 463 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |